| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>СОВЕТ КУКМОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОН СОВЕТЫ |
|---|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2020 елның 11 декабре Кукмара ш. № 32

Кукмара муниципаль районының 2021 елга һәм 2022 һәм 2023 еллар план чорына бюджеты турында

Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2021 елга һәм 2022 һәм 2023 еллар план чорына тәкъдим ителгән бюджетын караганнан соң, Кукмара муниципаль район Советы **карар бирде:**

**1 статья**

1. 2021 елга Кукмара муниципаль районы бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) Кукмара муниципаль районы бюджетының фаразланыла торган гомуми керем күләме 1 413 232 510,00 сум күләмендә;

2) Кукмара муниципаль районы бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 1 413 232 510,00 сум;

3) Кукмара муниципаль районы бюджеты дефициты (профициты) 0 сум

2. 2022 елга һәм 2023 елга Кукмара муниципаль районы бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) Кукмара муниципаль районының 2022 елга керемнәренең фаразланыла торган гомуми күләме 1 419 132 957,35 сум һәм 2023 елга 1 419 773 237,79 сум;

2) 2022 елга Кукмара муниципаль районы бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 1 419 132 957,35 сум, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 12 970 500 сум һәм 2023 елга 1 419 773 237,79 сум, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 26 754 900 сум;

3) Кукмара муниципаль районының 2022 елга бюджет дефициты (профициты) 0 сум, 2023 елга 0 сум күләмендә.

3. Кукмара муниципаль районы бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын түбәндәгечә билгеләргә:

2021 елга әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә;

2022 һәм 2023 елларга әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә;

2 **статья**

1. 2022 елның 1 гыйнварына торышы буенча билгеләргә:

Кукмара муниципаль районы бурыч йөкләмәләре буенча муниципаль бурычның иң югары чиге ноль сум күләмендә, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча ноль сум күләмендә.

2. 2023 елның 1 гыйнварына торышы буенча билгеләргә:

Кукмара муниципаль районы бурыч йөкләмәләре буенча муниципаль бурычның иң югары чиге ноль сум күләмендә, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча ноль сум күләмендә.

3. 2024 елның 1 гыйнварына торышы буенча билгеләргә:

Кукмара муниципаль районы бурыч йөкләмәләре буенча муниципаль бурычның иң югары чиге ноль сум күләмендә, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча ноль сум күләмендә.

**3 статья**

Кукмара муниципаль районы бюджетында Кукмара муниципаль районы бюджетының фаразланган керем күләмен 2021 елга әлеге карарга 3 нче кушымта нигезендә һәм 2022 һәм 2023 еллар план чорына әлеге карарга 4 нче кушымта нигезендә исәпкә алырга.

**4 статья**

1. Кукмара муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген әлеге карарга 5 нче кушымта нигезендә расларга.

2. Кукмара муниципаль районы бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары исемлеген әлеге карарга 6 нчы кушымта нигезендә расларга.

**5 статья**

Кукмара муниципаль районы Юл фондының бюджет ассигнованиеләре күләмен 2021 елга 28 900 мең сум, 2022 елга 30 400 мең сум, 2023 елга 30 500 мең сум күләмендә расларга һәм аларны 2021, 2022 һәм 2023 елларга Кукмара муниципаль районының гомуми файдаланудагы юлларында юл эшләре программасы чараларын тормышка ашыруга юнәлдерергә.

**6 статья**

1. Бюджет ассигнованиеләрен бюджет чыгымнары классификациясенең бүлекләре һәм бүлекчәләре, максатчан статьялары һәм чыгымнар төрләре буенча бүлүне расларга:

2021 елга әлеге карарга 7 нче кушымта нигезендә;

2022 һәм 2023 елларга әлеге карарга 8 нче кушымта нигезендә;

2. Кукмара муниципаль районы бюджеты чыгымнарының ведомство структурасын расларга:

2021 елга әлеге карарга 9 нчы кушымта нигезендә;

2022 һәм 2023 елларга әлеге карарга 10 нчы кушымта нигезендә;

3. 2021 елга гавами норматив йөкләмәләрне үтәүгә бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен 11 нче кушымта нигезендә 3 476 000,00 сум күләмендә, 2022 елга 3 476 000,00 сум һәм 2023 елга 3 476 000,00 сум күләмендә 12 нче кушымта нигезендә расларга.

**7 статья**

1. Кукмара муниципаль районы бюджетына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыру өчен Кукмара шәһәре

бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар күләмен муниципаль торак фондын капиталь ремонтлауга төзелгән килешү нигезендә 2021 елга 4 388 000 сум, 2022 елга 4 388 000 сум, 2023 елга 4 388 000 сум күләмендә исәпкә алырга.

Кукмара шәһәренә бюджетта югарыда күрсәтелгән максатларга тиешле субсидияләр бирүне карарга тәкъдим итәргә.

Кукмара муниципаль районы бюджетына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыру өчен җирлекләр бюджетларыннан башка бюджетара трансфертлар күләмен финанс контроленә төзелгән килешү нигезендә 2021 елга 607 000 сум, 2022 елга 607 000 сум, 2023 елга 607 000 сум күләмендә 13 нче кушымта нигезендә исәпкә алырга.

Кукмара муниципаль районы җирлекләренә бюджетларда югарыда күрсәтелгән максатларга тиешле субсидияләр бирүне карарга тәкъдим итәргә.

Кукмара муниципаль районы бюджетына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыру өчен җирлекләр бюджетларыннан башка бюджетара трансфертлар күләмен Җир биләмәләреннән файдалану һәм җир төзү кагыйдәләре булганда, дәүләт милке чикләнмәгән һәм җирлек территорияләрендә урнашкан җир кишәрлекләре белән эш итү буенча төзелгән килешү нигезендә 2021 елга 100 000 сум, 2022 елга 100 000 сум, 2023 елга 100 000 сум күләмендә 14 нче кушымта нигезендә исәпкә алырга.

Кукмара муниципаль районы җирлекләренә бюджетларда югарыда күрсәтелгән максатларга тиешле субсидияләр бирүне карарга тәкъдим итәргә.

**8 статья**

Җирлекләрнең балансслылыгын тәэмин итү чараларына ярдәм итү өчен җирлекләр бюджетларына дотацияләр күләмен расларга:

2021 елга 37 255 900 сум күләмендә, әлеге карарга 15 нче кушымта нигезендә бүлеп;

2022 елга 42 189 000 сум күләмендә, әлеге карарга 16 нчы кушымта нигезендә бүлеп;

2023 елга 39 525 800 сум күләмендә, әлеге карарга 17 нче кушымта нигезендә бүлеп;

**9 статья**

Кукмара муниципаль районы бюджетында Татарстан Республикасы бюджетыннан һәм җирлек бюджетларыннан алына торган бюджетара трансфертларның күләмен исәпкә алырга:

2021 елга 980 103 210,00 сум күләмендә, әлеге карарга 18 нче кушымта нигезендә бүлеп;

2022 елга 961 529 510,00 сум күләмендә, әлеге карарга 19 нчы кушымта нигезендә бүлеп;

2023 елга 932 775 610,00 сум күләмендә, әлеге карарга 19 нчы кушымта нигезендә бүлеп.

**10 статья**

1. Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты 2021 елга һәм 2022 һәм 2023 елларның план чорына муниципаль хезмәткәрләр, бюджет өлкәсе

учреждениеләре һәм оешмалары хезмәткәрләре санын арттыруга, шулай ук аларны тотуга чыгымнар артуга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуклы түгел.

2. Җирлекләрнең җирле үзидарә органнарына 2021 елга һәм 2022, 2023 елларның план чорына муниципаль хезмәткәрләр, бюджет өлкәсе учреждениеләре һәм оешмалары хезмәткәрләре санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итмәскә киңәш итәргә.

**11 статья**

Кукмара муниципаль районының бюджет акчасы калдыкларыәлеге муниципаль контрактларның шартлары нигезендә 2020 елда түләнергә тиешле Кукмара муниципаль районы исеменнән товарлар китерүгә, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә муниципаль контрактларга түләү өчен файдаланылмаган бюджет ассигнованиеләренең калдыгы суммасыннан артмаган күләмдә, Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты тиешле карар кабул иткән очракта, 2021 елда әлеге максатларга тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыруга юнәлдерелә.

**12 статья**

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык Департаментының Кукмара муниципаль районы буенча территориаль бүлеге килешү нигезендә һәм түләүсез нигездә Кукмара муниципаль районы бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне башкара.

**13 статья**

Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

**14 статья**

Әлеге карарны «Хезмәт даны» район газетасында бастырырга.

Район Башлыгы С. Д. Димитриев